КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 1 сентябрь г.Казань № 745

Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеше күзәтчелеге инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 1 сентябрь, 745 нче
карары белән расланды

Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда
инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген
тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне дәүләт тикшерүендә тотуны (алга таба – инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту) оештыру һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

2. Инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан түбәндәгеләрне башкарганда гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 5 өлеш нигезендә эшләрне башлап җибәрү турында хәбәр итү кәгазе алынган көннән төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының техник регламентлар, проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә туры килүенә ярашлылык турындагы бәяләмә (алга таба – ярашлылык турындагы бәяләмә) бирелгән көнгә кадәр проект документлары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза (дәүләт яки дәүләткә карамаган экспертиза) үтәргә тиеш булган яки модификацияләнгән проект документлары булып торган капиталь төзелеш объектларын (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлештә күрсәтелгән объектлардан тыш) төзегәндә;

капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләгәндә, шул исәптән төбәк һәм җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау буенча, мондый объектларның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык тасвирнамәләренә кагылышлы эшләр алып барганда (әгәр дә капиталь төзелеш объектларын (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 3 өлештә күрсәтелгән объектлардан тыш) реконструкцияләүне гамәлгә ашыруга проект документлары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза (дәүләт яки дәүләткә карамаган экспертиза) үтәргә тиеш булса).

3. Инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештырганда һәм гамәлгә ашырганда Инспекция Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән тәртиптә аттестацияләнгән экспертларны, Россия Федерациясенең илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләү турындагы законнары нигезендә аккредитацияләнгән, тикшерелә торган юридик зат, индивидуаль эшмәкәр белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелүче затка йогынты ясарга сәләтле затлар булмаган эксперт оешмаларын билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә хокуклы.

4. Инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту предметы – капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү барышында эшләр башкаруның һәм кулланыла торган төзелеш материалларының, шулай ук мондый эшләр нәтиҗәләренең техник регламентлар, проект документлары таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерү.

5. Инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерүләрне оештыруга һәм үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә карата, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 5 өлеш белән билгеләнгән тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләрен исәпкә алып, «Дәүләт тикшерүендә тотуны (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

6. Инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда Инспекциянең вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары, экспертлар, эксперт оешмалары, юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр белән хезмәттәшлек итә.

7. Инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә карата күчмә һәм документлар нигезендә тикшерүләр оештыру һәм үткәрү, таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын оештыру һәм үткәрү, ачыкланган хокук бозуларны кисәтү һәм (яисә) бетерү буенча Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган чаралар күрү ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

8. Инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту гамәлгә ашырганда административ процедураларның тәртибе, вакыты һәм эзлеклелеге Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2013 ел, 4 декабрь, 94 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты белән билгеләнә.

9. Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда инвалидлар өчен капиталь төзелеш объектларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфат затлары карарларына һәм гамәл кылуларына (гамәл кылмауларына) карата Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ тәртиптә һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.